Ислам нуры
«Диндә көчләү юк, ләкин өндәү һәм өйрәту бар»
(Коръән Кәрим. 2-256)
12+
№ 14 (690) 25 июль 2019 ел (1440, Зөлкагъдә) Дини-иҗтимагый газета 1995 елдан чыга

# Укыйбызмы?



Ислам динендә гыйлемгә бик зур игътибар бирелә. Коръән-Кәрим аятьләрендә дә, Пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.в.)нең хәдис-шәрифләрендә дә гыйлем алырга тиешлеге хакында турыдан-туры әйтелә. Пәйгамбәребез (с.г.в.) әйтте: «Гыйлем алу – һәрбер мөэмин-мөселман өчен фарыз», – диде.

Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте белән, бүген безнең белем алу өчен мөмкинлекләребез зур. Мәчетләр каршында дәресләр оештырыла, мәдрәсәләр эшли, дини профессиягә өйрәтүче уку йортларыбыз бар. Шундый уку йортларының берсе булып Чаллы шәһәрендә урнашкан "Ак мәчет" мәдрәсәсе санала. Мәдрәсәдә көндезге, кичке, читтән торып уку бүлекләре эшли. Укучылар өчен бөтен шартлар да булдырылган: тулай торак, җылы уку класслары, тәһарәтханәләр, ашханә, китапханә, актлар залы, спортзал бар. Көндезге бүлеккә 9-11 класс белемле 25 яшькә кадәр булган егетләр кабул ителә. 9, 10 класс белем белән килүчеләргә урта белем алу мөмкинлеге дә бар. Уку срогы – 3 ел. Укулар 1нче сентябрьдән башлана. Кичке бүлеккә төрле яшьтәге ир-атлар һәм хатын-кызлар кабул ителә. Укулар аерым төркемнәрдә алып барыла. Ир-атлар дүшәмбе, чәршәмбе һәм җомга көннәрендә кичке алтыдан унынчы яртыга кадәр, хатын-кызлар шимбә һәм якшәмбе көннәрне иртән 8дән дүртенче яртыга кадәр укыйлар. Уку срогы – 4 ел. Укулар 1 октябрьдән башлана. Читтән торып уку бүлегендә уку срогы 4 ел. Кабул итү сессиясе ир-атлар өчен октябрьнең 1нче дүшәмбесеннән, хатын-кызлар өчен октябрьнең 2нче дүшәмбесеннән 1 атна дәвамында була. Кышкы сессия: ир-атлар өчен 20 декабрьдән 31 декабрьгә кадәр, хатын-кызлар өчен 1 январьдан 10 январьга кадәр. Җәйге сессия: ир-атлар өчен 20 майдан 31 майга кадәр, хатын-кызлар өчен 1 июньнән 10 июньгә кадәр.

Адресы: Чаллы шәһәре, Яңа шәһәр, 2/14. Телефон: 8 (8552) 38-67-02.

Исламча һәм дөньяви профессиональ белем бирү өлкәсендә Рәсәй ислам институты һәм Казан ислам университетлары эшләп килә. Рәсәй ислам институтында бакалавриат программасы буенча «Теология», «Лингвистика», «Журналистика» юнәлешләренә, шулай ук магистратура программасы буенча «Теология» һәм «Лингвистика» юнәлешләренә документлар кабул ителә. Укыту көндезге һәм читтән торып алып барыла. Документлар 5 августка кадәр кабул ителә. Керү имтиханнары 7-10 августта узачак. Россия ислам институты дәүләт үрнәгендәге дипломнар бирә. РИИ студентлары уку вакытына армиядән кичектерү ала.

Казан ислам университетында документлар "Ислам фәне" һәм "Коръән фәне" юнәлешендәге "Дини оешмалар хезмәтчеләре һәм дини персонал әзерләү" юнәлеше буенча кабул ителә. Укыту көндезге, көндезге-читтән торып (кичке) һәм читтән торып уку формалары буенча алып барыла.

Укырга керү турында тулырак мәгълүматны РИИ һәм КИУ рәсми сайтларында «абитуриентлар» өстәмә битендә, шулай ук кабул итү комиссиясе телефоны буенча алырга мөмкин: 8 (843) 251-01-55. Кабул итү комиссиясе адресы: Казан шәһәре, Газовая урамы, 19 йорт, каб. 209.

Магистратура һәм докторантура дәрәҗәсендә Ислам дине белеме алырга теләүчеләр өчен Болгар ислам академиясе бар. Анда "Ислам хокукы" һәм "Ислам фикере һәм караш" юнәлешләре буенча белем алу каралган.

Укырга керү турында тулырак мәгълүматны БИА рәсми сайтында, шулай ук кабул итү комиссиясе телефоны буенча алырга мөмкин: 8 (843) 590-34-98. Кабул итү комиссиясе адресы: Казан шәһәре, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27.

# Балалар ял итә

Һәр елны Чаллы шәһәре мәчетләрендә балалар өчен җәйге рухи-сәламәтләндерү яллары үткәрелә. Бу елның җәйге айлары да әлеге чараларга бай. "Хәзинә" мөселман балалары клубында июньнән август ае ахырына хәтле төрле яшьтәге балалар өчен рухи-сәламәтләндерү курслары уздырыла. 5-7 яшьлек кыз балалар "Бәләкәч" дип аталган аланда ял итәләр. Алан барышында балалар Ислам дине нигезләре белән таныша, мастер-класслар үтә, паркларга ялга һәм экскурсиягә чыгалар. 1-12 июль көннәрендә "Әбүзәр" мәчетендә 7-15 яшькә чаклы 40 кыз бала өчен рухи-сәламәтләндерү курслары узды. Әлеге чара барышында балалар Коръән дәресләренә йөрделәр, бассейнда һәм зоопаркта булдылар. Ә "Тәүбә" мәчетендә 8-16 яшьлек ир балалар өчен Коръән уку курслары үткәрелә. Ул 8 июльдә башланды һәм 2 августка хәтле дәвам итәчәк. Әлеге курслар дәвамында балаларны хәләл ашату һәм ике тапкыр табигатькә походка алып чыгу каралган. "Ихлас" мәчете каршында да 8 июльдән 14



июльгә кадәр рухи-сәламәтләндерү курслары узды. Атна дәвамында балалар өчен дин һәм Коръән дәресләре, иртәнге зарядкалар, күңелле уеннар, тәмле төшке ашлар, туризм буенча мавыктыргыч һәм файдалы мастер-класслар, табигатьтә уеннар оештырылды. Курсларда катнашучыларның һәркайсына Мактау грамоталары һәм истәлекле бүләкләр тапшырылды.

# ТР МДН хәбәр итә

Болгарда VIII Мөселман яшьләре форумы тәгәлләнде. Ак мәчеттә җомга намазы укыганнан соң, делегатлар туган якларына юл тотты. Быел форум Россиянең төрле төбәкләреннән, шулай ук чит илләрдән 18-30 яшьлек 100 егетне һәм 100 кызны җыйды. Катнашучылар арасында Татарстан, Башкортстан, Удмуртия, Мордовия, Чувашия, Кырым республикалары, Оренбург, Чиләбе, Свердловск, Самара, Төмән өлкәләре, Ямал-Ненец автономияле округы, Мәскәү, шулай ук Казакъстан һәм Кыргызстан вәкилләре бар иде. Быелгы яшьләр җыены нәзарәт тарафыннан игълан ителгән Тәфсир елына багышланды.

***

"Татар-информ" мәгълүмат агентлыгында мөселманнарның Согуд Гарәбстанына изге хаж гыйбадәте башлануы уңаеннан Мәскәү – Симферополь – Казан видеокүпере уздырылды.Быел Россиядән хаҗга, узган ел белән чагыштырганда, 5 мең кеше күбрәк барачак. "Татарстан квотасы 1800 урынны тәшкил итте. Шулкадәр татарстанлы, 2018 елдагы кебек үк, республикабызның "ДУМ РТ Хаҗ" рәсми операторы программалары буенча изге Мәккә һәм Мәдинә җирләренә хаҗ кыла алачак", – дип мәгълүмат бирде Татарстандагы "ДУМ РТ Хаҗ" рәсми хаҗ операторы җитәкчесе Ранис хәзрәт Вахитов. 2019 елның 24 июлендә 196 кешедән торган беренче 4 төркем хаҗ кылырга китәчәк. Хаҗга барлыгы дин кардәшләребездән торган 36 төркем барачак. Республикабыз хаҗилары үз турларын Татарстандагы бердәнбер рәсми хаҗ-операторы «ДУМ РТ Хаҗ»ның 4 программасы буенча алды: Казаннан "Стандарт – барысы да кертелгән", "Супер эконом", Мәскәүдән "Супер эконом", "Стандарт минимум", бу программалар үз эченә туклану, яшәү, трансфер һәм очкыч белән барып кайтуны, шулай ук юридик, медицина һәм квалификацияле консультатив ярдәм күрсәтүне берләштерә. Бәяләр программага карап үзгәрә: эконом-программа – 170 мең сум, стандарт – 260 мең сум. Татарстаннан булачак хаҗиның иң өлкәненә 86 яшь, ә иң кечкенәсенә – 13 яшь.

# Әзерлек башланды

22 июль көнне Чаллы шәһәренең Сидоровка бистәсендә урнашкан үзәкләштерелгән корбан чалу мәйданчыгында Корбан бәйрәменә әзерлек буенча беренче киңәшмә узды. Киңәшмәдә Чаллы мөхтәсибәте, Комсомол районы администрациясе, Эчке эшләр идарәсе, шәһәр ветеринария хезмәте, янгын сүндерү, шәһәрне яктырту, коммуналь хезмәтләр, шәһәрне яшелләндерү, шәһәр транспорты предприятиесе вәкилләре катнашты. Аның барышында Корбан бәйрәменә карата үтәлергә тиешле вазыйфалар билгеләнде. Икенче киңәшмә Корбан бәйрәменә бер атна калгач узачак.



# Канәгать була белсәң..

**Йосыф хәзрәт ДӘҮЛӘТШИН,**
**Казанның Идел буе һәм Вахитов районнары имам-мөхтәсибе.**

Аллаһ бәндәләрне бар итте, ризык бирде. Теләгән бәндәсенә ризыкны күбрәк, теләгән бәндәсенә ризыкны азрак бирде. Хәмед белән шөкер итәм, гөнаһымнан Аңа кайтам. Ул ялгызы, юк аның тиңдәше. Мөхәммәд – Аның илчесе. Салават шәрифләребез аңа булсын.

Кешелек дөньясы диннән ерагайган саен, җәмгыятебездә тискәре сыйфатлар артканнан арта бара. Аллаһы Тәгалә мул, чиста итеп биргән суларның балы бетә, корсаклар тулы булса да, ризыкның бәрәкәте бетә. Кешеләр арасында туган ризасызлык тамыр җәя. Карыннан үткән ризык та, оят җирләрен яшерүче кием дә, утыртып йөрүче ат та ул авыруны канәгатьләндерә алмый. Канәгатьсезлек, ризасызлык авыруы белән агуланган бәндә тотып карардай ризык белән туя алмый, киеп карардай кием белән канәгатьләнә алмый, утырып йөрердәй ат, машинадан канәгать була алмый. Ихтыяҗы үтәлә, машинасы да бар, йорты яңгыр-давылдан саклый, ләкин кешегә ул җитми. Ләкин күбрәк булса, яхшы булыр иде ди. Аллаһы Тәгаләгә шөкер итми, булганына шөкер итәргә кирәк дип үз-үзен вәгазьләми. Күп булса да, ул бәндәгә җитми. Нинди генә нигъмәтләре булса да, Аллаһ нинди генә мул тормыш бирсә дә, ул бәндәгә барыбер җитми, чөнки ул авырган бәндә, сәламәт бәндә түгел. Аның тәне сәламәттер, ләкин күңеле авыру. Шушы канәгатьсезлек авыруы белән чирләү сәбәпле, аңа күп булса да, җитми. Җитәр дип уйлаган халәтенә ирешә икән, аннары барыбер җитми икән. Менә болайрак кирәк икән! Ни өчен җитми? Чөнки авыру, аның күзе һаман да өскә таба карый, “Әлхәмдүлилләһ, кайчандыр ул нигъмәтем дә юк иде, хәзер бар”, - дими. Өскә карый да: “Кара, ул миннән дә яхшырак”, - ди. Ялангач йөрми, киеме бар, “Аның киеме тагын да затлырак”, - ди. Аты бар, “Аның аты затлырак”, - дип, һаман өскә карый. Үзеннән түбән дәрәҗәдә, яманрак халәттә булучыларга күзен төшерә алмый. Табигатькә карасак, һәрбер нәрсәне төшерүгә караганда күтәрү авыррак. Күтәргәндә, җир тартып тора, шуңа күрә, күтәрү авыррак. Кулны күтәрү төшерүгә караганда авыррак. Ятактан тору авыррак. Күз байлык эзләсә, киресенчә, төшерергә авыр икән.

Яшь егет, урамда гаурәте күренгән хатын-кызны күрсә, күзен төшерә алмый. Канәгатьсез кеше дә күзен төшерә алмый. Пәйгамбәребез (с.г.в.) әйтте: “Үзеңнән баеракларга карама, ә ярлыракларга карап, шөкер ит”. Ризасызлык белән авыручы үзеннән өстенрәкләрне карый. Аңа җитмәгәч, бервакытта да бәхетле була алмый. Кешенең 10 байлыгы булса да, барыбер үзеннән өстен кешене табар. Аллаһның гадел үлчәве дә бар. Әгәр дә кешенең бер нәрсәсе артса, икенче нәрсәсе төшә, нәрсәседер төшсә, икенче нәрсәсе күтәрелә. Бер яктан камиллеккә ирешсә, икенче яктан кимчелеккә төшә. Гыйлем алып, кемнеңдер иманы куәтләнергә мөмкин, ләкин сәүдәсе кимеп китәргә мөмкин. Кемнеңдер сәүдәсе артып, гыйбадәте кимергә мөмкин. Шуңа күрә, кеше бервакытта да төгәл камиллеккә ирешә алмый. Ризасызлык белән агуланган бәндә бервакытта да үзе теләгән бәхеткә ирешә алмый, чөнки Аллаһ аңа бу хәлне бирми. Әгәр дә ризасызлык белән яшәгән кешегә шушы Җир шарының яртысын кисеп бирсәң, валлаһи, ул беренче төнне үк йоклый алмаячак, чөнки икенче яртысы кемгә икән дип борчылачак. Бөтенесен бирәсең икән, Марс кемгә икән диячәк. Кояшта кемнәр бар икән диячәк. Адәм баласының канәгатьсезлек авыруы зур бер сынау. Бу чирдән дәваланырга кирәк. Аллаһның биргән нигъмәтләрен күрә белергә, алар өчен шөкер итәргә кирәк. Шул вакытта Аллаһы Тәгалә киемнең дә, ризыкның да бәрәкәтен бирер. Ризык калориясе күп булганга туйдырмый. Ризыкта бәрәкәт булса, тамак туя. Шуңа күрә, Хандак сугышында сәхабәләр пәйгамбәребез (с.г.в.) белән ач булганда, хәтта, ачлыкны аз гына булса да басып торсын дип, корсакларына ташлар бәйләп куйдылар. Пәйгамбәребезнең күлмәге астында ике таш бәйләнгән иде, ул да сыналды. Бер сәхабә, пәйгамбәребезне кайгыртып, өенә кайтып, бер бәрәнне чалдырды. Хатынына: “Әзерлә әле бәрәнне, хәзер Аллаһның илчесен алып кайтып ашатыйк”, - диде. Кечкенә генә бәрәнне чалып, хәләл җефете шулпа пешерде. Бу сәхабә Пәйгамбәребез янына килеп, “Әй, Аллаһның илчесе”, - дип, колагына гына пышылдады. Сәхабәләр бик күп иде. Ә бәрән кечкенә булды. “Кечкенә генә ризык әзерләгән идек, әйдә, кайтып ризыклан”, - диде. Пәйгамбәребез (с.г.в.) чокыр эченнән чыкты да: “Кардәшебез безгә ризык әзерләгән. Әйдәгез, ашыйбыз”, - диде. Теге ризык әзерләүче сәхабә, хатыны янына кайтып болай диде: “Һәлак булдык, Аллаһның илчесе барлык сәхабәләр белән безгә кайта”. Чөнки ит шулкадәр кечкенә , ә сәхабәләр бик күп һәм ач иделәр. Бераздан теге сәхабә гаҗәпләнеп әйтә: “Барлык сәхабәләр дә туйганчы ашадылар, соңыннан Аллаһ илчесе белән бергә утырып ашадык”. Аллаһ бәрәкәт бирә икән.

Әгәр күпме генә ризык булса да, Аллаһ бәрәкәт бирми икән, кеше шул ризыктан бәхет күрә алмаячак. Канәгать булу ул зур нигъмәт. Аллаһ аны кемгә бирде, шөкер итсен, шатлансын. Пәйгамбәребез (с.г.в.) дога кылды: “Әй Аллаһ, биргән ризыкларында миңа канәгатьлелек бирсәң иде”, - диде. Аллаһтан муллык кына түгел, канәгатьлелек тә сорарга кирәк. Җир өстендә иң канәгать кеше Мөхәммәд пәйгамбәр (с.г.в.) булды. Зур-зур патшалар, кәрваннар белән алтынга күмелсәләр дә, ләкин пәйгамбәребез кебек разый булып яшәмәделәр. Пәйгамбәребезнең берничә көн мичендә уты янмаса да, аның кебек канәгать кеше булмады. Пәйгамбәребез (с.г.в) әйтә: “Беркөнне Аллаһ Мәккә үзәнлекләрен алтынга тутырырга тәкъдим итте. Ләкин мин, юк, кирәкмәс, Раббым дип әйттем. “Бер көн ач булыйм, бер көн тук булыйм. Әгәр тамагым ачса, Сине зикер итәрмен, әгәр тамагым тук булса, Сине шөкер итәрмен”. Әлхәмдүлилләһ, мөселман муллыкка ирешсә, Аллаһны мактый, сынаулар килсә, Аллаһны зикер итә. Пәйгамбәребез (с.г.в.) тормыштан канәгать булып, Аллаһ биргән сынауларны гайрәт белән кабул итүчеләргә шатлыклы хәбәр әйтте: “Түбә агачы җәннәттә булыр кемгә? Кемнең тормышы җитәрлек кенә булып, ислам динендә булса. Очын-очка ялгап, тормышын алып баручы кешегә булыр”, - диде. Аның сәхабәләре нинди зур канәгатьлелек, ризалыкта яшәделәр. Аллаһка шөкер иттеләр. Бервакытта да үзләреннән баерак яшәүчеләргә карап көнләшмәделәр. Әбү ад-Дарда әйткән: “Байлар зур йортларда яшиләр, без дә урамда түгел, байлар затлы киемнәр кияләр, без дә ялангач түгел. Аларның, бездән аермалы буларак, артык маллары бар”. Байның 20 машинасы булса, ул бит егермесендә дә йөри алмый. 20 өе булса, берсе дә җитә бит, 20се кирәкмәс. Күпме ризыклары булса да, 5 мәртәбә артык ашый алмый. Шул байлар кирәк кадәресен генә кулланалар да, артыгына карап сокланалар. “Әгәр без дә теләсәк, барабыз да, аларның малларына карап сокланабыз”, - ди. Һәрберебез сокланса да, артык маллар өчен без түгел, ә алар җавап бирәләр. Байның 3 катлы өенә карап, без дә сокланабыз. Ул да соклана, тик бөтен бүлмәләрендә дә яши алмас. Банктагы миллиардларга карап, ул да соклана, без дә сокланабыз.

Аллаһ Коръәндә әйтә: “Ир булса да, хатын-кыз булса да, кем Аллаһка иман китереп, изге гамәлләр кыла, аны яхшы тормыш белән яшәтербез”. Гали, Ибн Габбас дигән аятькә шундый тәфсир бирәләр: “Яхшы тормыш Аллаһ биргән канәгатьлелек булыр. Кемгә канәгатьлелек бирми, шул бәхетсез була”. Кем канәгать булды, аның тормышы яхшырыр, кем комсыз булды, аның ахмаклыгы артыр. Шуңа күрә, Раббым һәрберебезгә канәгатьлелек насыйп итсен. Бик күпләр авырый торган ризасызлык дигән авырулардан безгә шифа бирсен.

## Колак салсаң, үкенмәссең

***Гүзәл холыклы кеше нинди була?***

1. Тугрылык. Гүзәл холыкларның падишаһы – тугрылыктыр.

2. Үз хатаңны үзең тану. Бу сыйфат кешенең югары күтәрелүенә бер дәлилдер.

3. Кыю булу. Бу сыйфат – сүзне ачык сөйләү һәм күңелдәге фикерне югалып калмыйча, гади итеп бәян итүдән гыйбарәттер.

4. Үз вазифаңны үзең белү. Бу сыйфат һәркемнең үзендә булырга тиеш, кисәтеп әйтүне көтеп торырга тиеш түгел.

5. Вакытында эшләү. Бер эшнең үз вакытыннан кичегеп эшләнүе бик күп эшләрнең бөтенләй эшләнми калуына сәбәп булуы мәгълүм.

6. Үз уеңда нык торучанлык һәм түземлелек. Бу сыйфат үзең дөрес дип санаган фикереңнән кире кайтмауда ачык күренә.

7. Үз-үзеңә ышану. Бу сыйфат беркемнән дә ярдәм көтмичә, үз-үзенә нык ышанган, авырлыкларны җиңеп, алга баручы кешедә ачык чагыла.

8. Намус. Кешенең бөтен кыйммәте – намуслы булуында. Адәм балаларын фәрештәләр дәрәҗәсенә күтәрә торган нәрсә – намус булып, хайваннардан да түбән дәрәҗәгә төшерә торган нәрсә – намуссызлыктыр.

9. Авырлыкка түзә белү. Бу сыйфат, һәбер кечкенә эшкә әһәмият бирмәү һәм зур эшләрдә дә үз-үзен яхшы тотып, салкын кан белән фикер йөртүдә ачык күренәдер.

**Риза ФӘХРЕДДИН**

## БЕЛӘСЕЗМЕ?

Кемнәргә һәм кайчан хаҗ кылу дөрес?

Хаҗга бару фарыз булуның шартлары:

1. Мөселман булу.
2 Бәлигъ булу.
3. Үз акылыңда булу.
4. Ирекле булу.
5. Хаҗ кылуның фарыз икәнлеген белү.
6. Кешенең хаҗга бару һәм аннан кайту юлына җитәрлек акчасы булу.
7. Хаҗга китүченең ул хаждан кайтканчыга тикле гаиләсенең яшәвен тәэмин итәрлек мал-мөлкәте булуы.

Хаҗны башкаруның шартлары:

1. Сәламәт булу (сукыр, бик карт һ.б. шуның шикелле кешеләрнең хаҗ кылулары фарыз түгел, ләкин, җитәрлек акчага ия булсалар, башка кешене яллап үзләре өчен хаҗ кылуны йөкләве тиеш була).
2. Хаҗга бару юлының тыныч-имин булуы.
3. Хатын-кыз хаҗга бары тик ире белән яки бүтән мәхрәм (кияүгә чыгарга ярамаган ир кеше) белән баруы.
4. Иреннән аерылган хатын-кыз гыйддәт вакыты узганнан соң хаҗ кыла ала.

# Корбан чалу

*"Шуның өчен намаз кыл син, корбан чал Раббың өчен". ("Кәүсәр", 108: 2)*

Корбанны Корбан бәйрәменең алдагы өч көнендә чалалар, ләкин моны бәйрәмнең беренче көнендә эшләсәң яхшырак. Бәйрәм намазы укылган шәһәрләрдә һәм авылларда корбанны шул намаздан соң чалалар. Бәйрәм намазы укылмаган авылларда корбан чалуны таң аткач башкаралар.

Үзе чала белгән кеше корбанны үзе чала, белмәгән кеше исә берәр бүтән мөселманга әйтеп чалдыра ала. Түбәндәге ниятне әйтергә кирәк: «Йә Аллаһы Тәгалә, ризалыгыңны алыр өчен корбан китерәм». "Бисмиллаһи, Аллаһу әкбәр" сүзләрен әйтеп, суйган вакытта тәшрик тәкбирен әйтеп торырга кирәк: «Аллаһу әкбәр, Аллаһу әкбәр, ләә иләһә илләллааһ. Аллаһу әкбәр, Аллаһу әкбәр вә лилләһил хәмд» ("Аллаһ бөек, Аллаһ бөек, Аллаһтан башка илаһ юк. Аллаһ бөек, Аллаһ бөек, бар мактаулар Аллаһка").

Корбан итен кешеләргә таратырга яисә үзеңдә калдырырга була. Аны өч өлешкә бүлсәң хәерлерәк: бер өлешен туганнарга һәм дусларга таратырга, икенче өлешен фәкыйрьләргә өләшергә, ә өченче өлешен үзеңә калдырырга.

Корбан итеп чалынган хайванның итен сатарга яисә итчегә түләр өчен кулланырга ярамый, мәкруһ була. Тиресен үзең кулалансаң була, һәм шулай ук аны мохтаҗларга яисә хәйрия оешмасына бирергә дә була. Корбан итен мөселман булмаган кешеләргә күчтәнәч итеп бирергә ярый.

**(«Ислам дине нигезләре»ннән).**

## ӘДӘБИ СҮЗ

### Күңел тынычлыгы бирсәңче...

*Без Алладан нидер сорыйбыз гел,*
*Эчтән генә теләк телибез.*
*Ни сорарга кирәклеген кайчак*
*Үзебез дә төгәл белмибез.*
*Кемдер сорый аннан байлык, муллык,*
*Бик күбебез сорый саулыкны.*
*Ә мин сорыйм күңел тынычлыгы –*
*Алыштырмас бөтен байлыкны.*
*Күңел тыныч булса – яшәү рәхәт,*
*Тормыш ямьле була һәр көндә.*
*Бер сәбәпсез җаның бәргәләнсә,*
*Кояш сүнә күңел күгендә.*
*Күңел тынычлыгы бирче, Раббым,*
*Салма зинһар борчу-хәсрәткә.*
*Яши алсак иде гомерләрне,*
*Кайгы күрми, бары рәхәттә!*

**Гөлара ШӘРИПОВА, Арча.**

# Исрафчылык

Әссәләмүгаләйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәракәтүһү, кадерле кардәшләребез!

Исраф сүзе – ул чамасын белмичә, саксыз куллану, артыгын куллану. Изге Коръәннең "Әгъраф" сүрәсендә: "Аллаһ исраф итүчеләрне яратмый", – диелгән. Ягъни ул гөнаһ булып тора. Исраф төшенчәсе бик киң, ул барлык гамәлләргә дә кагыла. Исраф мадти һәм рухи була ала. Мәсәлән, мөлкәтеңне файдасызга яки хәрәмгә тоту, киемнәрне сакламыйча кию, кирәгеннән артык ризык әзерләү яки ашау һәм башка шундый гамәлләр - ул матди исраф. Вакытны, сәламәтлекне, акылны дөрес юнәлештә кулланмау рухи исрафка керә. Исламда исрафның барча төре дә тыелган. Без бүген әйберләр сатып алу мәсьәләсенә тукталырбыз. Күпләр кибетләрдә йөрергә ярата, кемдер кирәк булганда гына йөри. Ләкин кайчак бер генә нәрсә алам дип базарга керәсең, ә анда тегендә нәрсәнедер мактыйлар, төрле ташламалар кызыктыра башлый... һәм уйламаган артык нәрсәләр тутырып кайтыла. Шайтан вәсвәсә кылып, артыгын алдыртмасын өчен, Аллаһ безне шайтаннан саклап торсын өчен, Пәйгамбәребез галәйһиссәләм безгә дога өйрәтеп калдырган. Аны кыскартып болай укысак була: "Ләә иләһә илләллаһү вәхдәһү ләә шәрикә ләһ, ләһүль мулкү вә ләһүль хәмд, вә һувә гәлә күлли шәй иң кадийр". Мәгънәсе: "Аллаһтан башка иләһ юк, Ул бер генә, Аның тиңдәшләре юк. Бар хакимлек Аныкы. Бөтен мактаулар Аңа. Һәм Аллаһның бөтен нәрсәгә көче җитә". Шушы доганы даими укысак, әҗерләр дә җыярбыз, шопинг дигән чир дә эләкмәс. Шопинг чире белән авыручылар яңадан-яңа әйбер сатып алудан ләззәт табалар һәм бик күп вакытларын базар-кибетләрдә йөреп уткәрәләр. Кайбер бүгенге заман гаиләләрендә балалар кечкенәдән үк сәүдә үзәкләрендә үсә дисәк тә була. Сәүдәнең нык таралуы – ахырзаманның кече билгесе. Хәзер ирләр генә түгел, хатын-кыз сәүдәгәрләр дә бик күп. Кая карама зур кибетләр, зиннәтле сәүдә үзәкләре. Сәүдә үзе – сөннәт гамәл, пәйгамбәребез галәйһиссәләм дә сәүдәгәр булган. Ләкин кешеләрнең купшылыкка, байлыкка чамадан тыш омтылуы артык сатып алуга этәрә, ә кайбер сатучылар, зур керемнәр өмет итеп, шәригать чикләрен үтәләр. Бу барысы да исраф, булганыннан канәгать булмау. Ә канәгатьсезлек – ул Аллаһка шөкерсез булу! Безгә Аллаһтан бу дөньяда билгеле бер өлеш, ризык бүлеп бирелгән. Безнең ахирәттәге хәлебез шул Аллаһ нигъмәтләрен дөрес куллануга бәйле булачак. Пәйгамбәребез галәйһиссәләм: "Кыямәт көнендә кеше 4 сорауга җавап бирмичә урыныннан кузгалмас", - дигән. Шул сорауларның берсе: "Милкеңне нинди юл белән таптың (ягъни хәләлме, хәрәмме) һәм аны нәрсәгә файдаландың?" Матди байлыкны файдалану мәсьәләсендә без бик җиңел генә исраф итүчеләр исемлегенә эләгә алабыз, барыбызны да Аллаһ сакласын. Коръәни Кәримнең "Әл-Исра" сүрәсендә: "Исрафчылар – шайтан кардәшләре, ә шайтан Раббысына шөкерсез," – дип әйтелә. Берәр нәрсәнең исраф яки исраф түгел икәнен ничек аңлап була соң?

Үз-үзебезгә алдамыйча, ихластан җавап бирергә тиешбез: бу әйбер миңа ни дәрәҗәдә кирәк? Бу әйбергә ихтыяҗ нык зурмы, әллә ансыз да торып буламы? Мин аны озак файдаланачакмынмы? Мин аны нинди ният белән алырга җыенам? Ният дөрес булырга тиеш. Акчам барында, күбрәк ләззәт алып калырга тырышыйм яки башкалардан өстен булыйм, уздырыйм әле, башкаларны шаккаттырыйм әле, минем бай икәнемне белсеннәр, мактасыннар әле яки башка шундый ниятләр белән әйберләр алырга ярамый. Нәфескә болай алдану – зур гөнаһ. Зур хәлифәт патшасы буларак, Пәйгамбәребез галәйһиссәләм байлыкка күмелеп яши ала иде. Ләкин ул үз теләге белән бик нык тыйнак яшәгән. Пәхтә һәм гади итеп киенгән. Киемнәрен, үзе ямаулар салып, тузганчы кигән. Кечкенә өендә дә бер артык нәрсәсе булмаган. Сөекле Пәйгамбәребез үз тормышы белән безгә сакчыл, икътисадлы яшәү үрнәген күрсәтеп калдырган.

**Әлфия МӨДӘРИСОВА,**
**«Хәзинә» клубы мөгаллимәсе.**

*Безгә язалар*

# Чормада сакланган шәҗәрә

Җәйнең соңгы ае. Озакламый көз. Бакчада алма өлгергән чак. Кояш күтәрелгәнче дип, чиләгемне асып, коелган алмаларны җыярга бакчага чыктым. Җирдә череп әрәм булалар бит, дип алмаларны чиләккә тутырам. Чиләккә төшкән алмаларга кушылып кошлар сайрый. Аяк астындагы чыктан аягым да юешләнде. Быел алма күп булган. Менә ичмасам! Алмасының күплегеннән алмагач сыгылып төшкән. Артык авырлыгыннан арыныргa теләп җиргә бушата, бахыр. Тулган чиләгемне тиз генә ләгәнгә тондырам да тагын чиләгемне тутырам. Боларны төшкә хәтле чистартып, турап, чормага менгерергә кирәк. Киптерелгән алма кышкы компот, пирог эченә ярап куя. Мал бит.

Алмаларны кулга алуга, балачак искә төшә. Өлгереп тә бетмәгән алмаларны тозга манып ашаган һәй ул чаклар! Дәү әти белән дәү әни дә исән иде ул чакта. Әнә хәзер йортлары гына утырып калды һәм шул алмагачлар. Елларда кайткалап, йортны җыештырып, кураларын, алмаларын җыеп китәргә генә калды инде. Нишләтәсең! Бакчадагы алмалар да җиргә төшә, череп туфракка әйләнә.

Әллә нишләп иртәдән бирле хәтирәләр яңартам әле. Тиз генә алмаларны җыеп, чормага киптерергә менгерәсем бар бит!.. Алмаларны төш алдыннан гына турап бетердем. Аларны алма чиләгенә салып, өй кыегына терәтелгән баскычтан күтәрeләм. Баскыч тимерен тимер дә бит, барыбер шикләндерә. Бер кул белән чиләкне тотып, икенче кул белән баскычка ябышып үрмәлим. Картаеп калган авыл морҗалары миңа сәлам бирә. Сәламнәрен алып чорма ишегенә якынлашам. Инде ничә еллар чормага җәелгән җирле туфрак та тузанга әйләнгән. Аяк тиюгә бата. Эскәтеремне тузан-туфракка җәеп, өстенә алмаларымны таратам. Монда алар бик тиз кибәрләр!

Түрдәге тәнлек тәрәзәдән төшкән кояш нурлары күзне чагылдыра. Ничә мәртәбә шунда менеп, шул очка барып җитә алганым юк һаман. Шул тәнлек тәрәзәдән аргы якка бик тә күз саласым килә. Тәрәзәгә таба атлыйм. Кыектагы өй морҗасы – мәһабәт багана кебек, балчыгы гына бераз купкан. Тәрәзәгә кунган тузанга хат язарлык. Эх, чүпрәк тә эләктермәгәнмен! Бер очтан тузанын да сөртеп төшерә идем. Ярый! Менгән-менгән, күлмәк итәгем белән булса да тузанын сөртергә кирәк дип, тәнлек тәрәзәсенең кыегына үрелдем. Тәрәзә янәгыннан ниндидер күн тәрәк алдыма килеп төште. Бик сәер нәрсә! Үзе тире күнгә төрелгән, төсе дә уңмаган. Нәрсә булыр бу? Бераз гына шомландыра. Бисмилламны әйтеп, күнне чишәм. Күн эчендә яулык, яулык эчендә сап-сары кәгазьләр. Ниндидер борынгы язулар! Кеше кулы белән язылган кульязмалар. Гарәпчә хәрефләрне җыям: Исхак углы Гыймран, Гыйлман улы Гыймран... Бер дәфтәр язу! Гыйлман – әниемнең әтисе бит! Бабамның йорты бит бу, бабам чормасы, бабам алмалары!

Нәсел шәҗәрәсен болай чормада яткыру килешмәс, алмагачның алмалары кебек төрле якка таралышкан туганнарны барларга да, ата-бабаларыбыз рухын тергезергә. Киләчәк буынга бу ядкарьне тапшырып калдырырга кирәк...

**Гөлфия НАСЫЙБУЛЛИНА.**

# Уйлана беләбезме?

Аллаһ Раббыбыз әйтә: «Бәндәләр Миңа берәүләре акыл белән килерләр, берәүләре авыру белән килерләр». Авырса, адәм баласы терелә алмас, диделәр. Могҗиза булды, Аллаһтан бүләк булды – терелеп куйды. Йә нәзер әйтте, йә булмаса, уйланды: кара инде, беркем ярдәм итә алмас кебек иде, булды бит, аякка бастым бит, дияр. һәм Аллаһка якын килер, шуның аркасында иманы ныгыр. Берәүләр байлык аркылы килерләр, берәүләр -ярлылык аркылы, берәүләр - кайгы аркылы, берәүләр шатлык аркылы килерләр, - диде Аллаһ Тәгалә. Ничек килсәләр дә, Минем өчен алар тигез, - диде. Әмма адәм баласын Аллаһ Тәгалә акыл белән зиннәтләгән икән, ул фикерләсен. Аллаһ Раббыбыз Коръәндә бик күп урыннарда әйтә: җир-күк төзелешләрендә, тарихларда, кешеләрнең яшәешләрендә, хайваннарның хәтта үрчүләрендә, бал кортының төзелешләрендә дә Минем барлыгымның хикмәте бар, - ди. - Бал кортын гына алсагыз да, - ди, - кечкенә генә бер бөҗәк, шунда бал да урнашкан, агу да урнашкан, берсе белән берсе катышмаган. Аларның яшәешләрен карасагыз да сезгә гыйбрәт алырга бик күп нәрсәләр бар. Аллаһның менә шушы хикмәтләре белән, шушы дөньяның яратылышы, төзелеше турында фикерләп, уйлап, адәм баласы Аллаһның барлыгына инанырга тиеш.

**Җәлил хәзрәт ФАЗЛЫЕВ,**
**Татарстанның баш казые.**

# Үзең теләгәнне аңа бирерсең!

*(Имам Әбү Хәнифә турында гыйбрәтле хикәят)*



Бер тол ир, каты авырып китеп терелмәячәген аңлагач, үләр алдыннан күршесен чакыра да, мең дирхәм салынган янчыгын тапшырып әйтә:

- Минем кечкенә улым үскәч, шушыннан үзең теләгәнне аңа бирерсең...

Малай үсеп балигъ булгач, бу кеше аңа мәсьәләне кыскача аңлата да, “әманәтне үтим, минем өстә калмасын” диптер инде, фәкать буш янчыкны гына бирә. Егет Әбү Хәнифә янына барып, вафат булган әтисенең васыяте һәм күршесенең аңа буш янчыкны гына биргәне турында сөйли. Шуннан соң имам шул намуссыз кешене чакыртып, аңа болай дип әйтә:

- Бу егетнең әтисе үләр алдыннан сиңа янчыкны тапшырганда, “шушыннан үзең теләгәнне аңа бирерсең” дип әйткән иде. Димәк, син вафат булган күршеңнең улына мең дирхәмне бирергә тиеш.

- Ничек инде шулай? – диде аптырап теге кеше.

- Менә шулай! – дип җавап кайтарды имам, хәйләкәр елмаеп. – Син бит мең дирхәмне үзең өчен теләдең, ә васыять шарты буенча, үзеңә теләгәнне син бу егеткә тапшырырга тиеш!

Имам-әгъзамның шушы хикмәтле дә, хәйләле дә карарын берничек тә кире кага алмаган теге ир егеткә мең дирхәмне бирергә мәҗбүр була.

Әлеге хикәяттә зур хикмәт тә, гыйбрәт тә бар, чөнки анда чын мөселманның холык-әдәбен чагылдыра торган бик мөһим кагыйдә турында сүз бара. Ә ул кагыйдә шундый: үзеңә нәрсә телисең, башкаларга да шуны telә! Мөбарәк хәдисләрнең берсендә бу хакта болай диелә: “Үзеңә теләгәнне башкаларга теләми торып, берегез дә чын мөэмин була алмый».

**Ришат КУРАМШИН әзерләде,**
**Кукмара мәдрәсәсе мөдире.**

*Балалар өчен*



## Таңда торсаң...

Таңда торып кара әле,
Таң никадәр серле, ямьле!
Юрганыңны син ал әле,
Бәрәкәтле шул таң мәле!

Йокың да бик килөдер шул,
Йокы бигрәк тәмле шул ул!
Ә син җиңүчеләрдән бул,
Нәфсеңә һичбер куйма юл!

Таңда торып кара әле,
Таң шундый әһәмиятле.
Пәйгамбәр дә шулай иткән,
Иртә торырга өйрәткән.

Тәһарәтеңне син алып,
Намазлыгыңа син басып,
Укыгач та намазыңны,
Бел бәхетле булуыңны!

Таңда торып кара әле,
Ихластан дога кыл әле,
Нәфсеңне әйдә җиң әле,
Булырсың, балам, җәннәтле!

## Табышмаклар

Коръән китабы аңа инде,
Ул туганда фил елы иде.
Барыбыз да хөрмәтлибез,
Нинди Пәйгамбәр дип әйтәбез?
*(Мөхәммәд)*

Ике улы да булган Пәйгамбәр,
Исхак һәм Исмәгыйль исемлеләр.
Аллаһның дусты дип дәшкәннәр,
Булган ул кайсы Пәйгамбәр?
*(Ибраһим)*

Иксез-чиксез диңгездә,
Бер сәбәпле булган ул балык эчендә...
Гаебен-хатасын таныган,
Бик ихластан дога кылган!
*(Юныс)*

**Алинә ХӘБИБУЛЛИНА,**
**«Асыл зат» түркеме җитәкчесе.**

## Саулыгым – байлыгым

# ӘРЕМ

Әрем белән дәвалауга элек-электән игътибар биргәннәр. Әрем – эчәклекне чистартырга сәләтле. Дәвалану өчен 100 г әрем алына. Кипкән әремне бәрәр чәй калагы чамасында өч сәгать саен кабып, әйбәтләп чәйнәргә, артыннан су йотып куярга кирәк. Өч көннән соң көнгә дүрт тапкыр гына каба башларга. Ашау вакытына яраклаштыруның кирәге юк. Дәвалану курсы – бер атна. Шушы рәвешле дәвалану бабасырдан, суалчаннан, геморройдан, зарарлы бактерияләрдән коткара. Мондый чистарынуны елга ике тапкыр кабатларга кирәк. Үзенең хасиятләре ягыннан әрем көчле дарулар белән бер рәткә куела. Шуңа күрә тиешле дозаны саклау мәҗбүри. Доза артып киткәндә йокысызлык, бармаклар калтырау, йөрәк кагу, күңел болгану күзәтелә. Әремнең органик составы кеше ашказанындагы үт сыеклыгына тәңгәл килә. Менә шуңа күрә ашказаны асты бизе һәм үт юлы авыруларын дәвалаганда, ашкайнату сүлпән булганда, эч күпергәндә, авыздан ис килгәндә әрем киң файдаланыла. Әрем төнәтмәсе татлы ризыкларга хирыслыкны бетерә. Аның шушы сыйфаты шикәр



чирле кешеләргә әйбәт ярдәм итә.

Әремнең спиртлы төнәтмәләре агулы була. Суда әзерләнгән әремдә агулы матдәләр булмый диярлек. Әрем төнәтмәсе – бик көчле дару. Кайбер очракларда, әйтик, ашказаны-эчәк трактын дәвалаганда, нәтиҗәсе сизелерлек була. Йөкле һәм бала имезүче хатыннарга, ашказаны җәрәхәте, гастрит борчыганда, әчелек түбән очракларда, үт куыгында таш кузгалганда әрем белән дәваланырга ярамый. Энтероколит, астма чирләреннән дә табиб күзәтүе астында гына әремнән файдаланырга мөмкин.

*(Фотолар интернеттан алынды)*

**Нәшире**
**Иршат Гыйльметдин улы ШӘЙХАТТАР**
**Баш мөхәррир**
**Муллагалиева А. Г.**
**Тел.:** (8552) 70-51-09
**Факс:** (8552) 70-51-45
* * *
**Оештыручылары:**
Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан җөмһүрияте мөселманнары Диния нәзарәте, “Ислам нуры” дини эшмәкәрлек Үзәге

Газета мәкаләләрен күчереп басканда аларның “Ислам нуры”ннан алынганын күрсәтү мәҗбүри.

Редакциягә килгән хатларда авторларның стиле саклана.

**Хатларны 423802, Чаллы Үзәк ур., 72 адресы буенча юллау кирәк.**

**Электрон хатлар өчен:**
islamgazeta@mail.ru

Мөселманнар арасын бозуга, үзара каршылыкларга китерергә мөмкин булган хатлар, шикаятьләр газетада басылмый.

Дин-шәригать мәсьәләләренә кагылышлы язмалар, укучы сораулары Татарстан Диния нәзарәтенең баш казые, Чаллы төбәге мөхтәсибәтенең гыйльми Советы тарафыннан өйрәнелә һәм аларга җавап бирелә.

Россия Федерациясе матбугат, телерадиотапшырулар һәм массакүләм коммуникацияләр Министрлыгының Идел буе төбәкара территориаль идарәсендә ПИ № 7-0997 саны белән 2001 елның 15 ноябрендә теркәлде.

“Роспечать” агентлыгы каталогына кертелгән, язылу ел әйләнәсендә Россия Федерациясе буенча алып барыла.

Айга ике мәртәбә чыга.

**Тиражы: 1500**
**Индексы 54149**
* * *

Хөрмәтле укучыбыз!

Газетабызны укып чыккач, аны туганнарыгызга, танышларыгызга, тапшырсагыз иде. “Ислам нуры”ның һәр саны кулдан-кулга күчеп динебезне таратырга ярдәм итсә иде. Әмин.

Шулай ук укучыларыбыз, Коръән аятьләре язылу сәбәпле, газетаны кирәкмәгән урыннарга ташлаудан сакланырлар дип ышанабыз.

* * *
Газета компьютерда җыелды, офсет ысулы белән “Ислам нуры” басмаханәсендә басылды.

**Нәшир, типография һәм редакция адресы:**
**423802, Яр Чаллы, Үзәк урамы, 72**
**Басарга кул куелды:**
**график буенча 25 июль 16 сәг.**
**фактта 25 июль 16 сәг.**
**Бәясе ирекле**